СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.05.2020 с. Сарманово № 232

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2018 нче елның 6 июнендәге 125 нче номерлы «хезмәт (вазифа) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Уставына, Сарман муниципаль районы Советына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге УП-1092 номерлы указы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Сарман муниципаль районы Советының 2018 нче елның 6 нчы июнендә кабул ителгән 125 нче номерлы «хезмәт (вазифа) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлекне киләсе эчтәлектәге 3.2.6 пункт белән тулыландырырга:

«3.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган мотивлаштырылган бәяләмәләр үз эченә алырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә уведомлениеләрдә бәян ителгән мәгълүмат; б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынучы оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук

әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3, 3.11 пунктлары яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы Рәисе Ф.М.Хөснуллин